КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 ноябрь г.Казань № 896

«Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында» 2016 ел, 17 ноябрь, ТРЗ-82 нче Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында

«Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында» 2016 ел, 17 ноябрь, ТРЗ-82 нче Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Азык-төлек продуктларының сыйфатын яхшырту һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара яраштыру советын (алга таба – Яраштыру советы) төзергә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесе турындагы нигезләмәне;

Яраштыру советы турындагы нигезләмәне;

Яраштыру советы составын;

«Татарстан Республикасында азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында» 2016 ел, 17 ноябрь, ТРЗ-82 нче Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар планын («юл картасын»).

3. Яраштыру советына 2018 елның 1 гыйнварына кадәр Яраштыру советы составын һәм аныж эшче органнары вәкаләтләрен расларга һәм «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен алу һәм аны файдалану хокукыннан мәхрүм итү тәртибе турындагы, «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесен алуга карата таләпләр турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына түбәндәгеләр буенча чаралар күрергә:

азык-төлек продуктларының сыйфатын яхшыртуны һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү максаты белән федераль башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе, башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне һәм мәгълүмат алмашуны оештыру;

«Милли сәүдә маркасы» системасында азык-төлек продуктларының сыйфатын яхшыртуны һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүне стимуллаштыруга юнәлдерелгән тармак чараларын бергә туплау.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин

«Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесе турындагы нигезләмәгә кушымта

«Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесе сурәте

НАЦИОНАЛЬНАЯ
ТОРГОВАЯ
МАРКА

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 21 ноябрь, 896 нчы
карары белән расланды

«Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесе турында
нигезләмә

1. Бу Нигезләмә «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесе (алга таба – мәгълүмат билгесе) тасвирламасын, шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Мәгълүмат билгесе азык-төлек продуктлары, материаллар һәм әйберләрнең (алга таба – азык-төлек продукциясе) сыйфатын яхшыртуны һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар буларак «Милли сәүдә маркасы» системасын кертү максатларында гамәлгә куелды.

3. Мәгълүмат билгесе кулланучыларга һәм башка кызыксынучы затларга бу азык-төлек продукциясендә геннарны модификацияли торган организмнарның булмавы, норматив документлар белән билгеләнгән азык-төлек продукциясенең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына карата таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән тамга булып тора.

4. Мәгълүмат билгесе тамгасында Татарстан Республикасы Дәүләт флагы төсләре кулланыла. «МИЛЛИ СӘҮДӘ МАРКАСЫ» дигән сүз тамгасы оригиналь шрифт белән кириллицада башкарылган. Сүзләр бер-берсе астына урнаштырылган. Хәрефләрнең озынлыгы өстән аска таба зураеп бара. Сүз тамгасыннан сулда урнашкан график билге берсе астында берсе урнашкан төрле зурлыктагы яфракларның стильләштерелгән сурәте булып тора. Өстәге зур яфрак уртасыннан киселгән итеп ясалган. Мәгълүмат билгесенең төсе – кызыл-яшел язулары булган ак фон. Яфраклар төсе – яшел һәм кызыл.

Мәгълүмат билгесенең сурәте бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада китерелә.

5. Билгенең зурлыгы аның элементларының төгәллеген һәм аерылып торуын гади күз белән дә гарантияләргә тиеш. Мәгълүмат билгесе сурәте зурлыгы азык-төлек продукциясенең күләменнән һәм формасыннан, мәгълүмат билгесен язу урыннан чыгып билгеләнә.

6. Мәгълүмат билгесе типография ысулы белән, махсус әзерләнгән келәймә ярдәмендә яки үзе беркә торган марка рәвешендә төшерелергә, шулай ук аның күренеп торуын тәэмин итә торган башка ысул белән файдаланырга мөмкин.

7. Мәгълүмат билгесе аның сурәте нигезендә тулысынча төшерелә, сурәтнең аерым элементларын төшерү рөхсәт ителми.

8. Мәгълүмат билгесен кулланганда аның сурәте ул төшерелә торган өслектән аерылып торырга тиеш.

9. Мәгълүмат билгесе сурәтен азык-төлек продукциясенә турыдан-туры төшереп булмаганда, ул төрү материалына (тарага) төшерелә. Мәгълүмат билгесе чыганагы азык-төлек продукциясенә яки төрү материалына (тарага) әлеге чыганакның келәймә сугылган азык-төлек продукциясенә каравына каршы килүне булдырмый торган ысул белән беркетелә.

10. Мәгълүмат билгесен алу һәм аннан файдалану хокукыннан мәхрүм итү тәртибе, шулай ук мәгълүмат билгесен алуга карата таләпләр (алга таба – Тәртип һәм Таләпләр) Азык-төлек продуктларының сыйфатын яхшыртуны һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара яраштыру советы тәкъдимнәре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

11. Мәгълүмат билгесен хокукый яклауны тәэмин итү һәм булдыру «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

12. Азык-төлек продукциясе җитештерүчеләр, оештыру-хокук рәвешләренә, милек рәвешләренә һәм урнашу урынына карамастан, мәгълүмат билгесеннән файдалану хокукын алу өчен «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә гариза бирү тәртибендә бертигез, ирекле нигездә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

13. Мәгълүмат билгесен файдалану азык-төлек продукциясенә, төрү материалына (тарага), техник һәм иярчен документларга келәймә сугу, шулай ук азык-төлек продукциясенә әлеге билге белән келәймә сугу хокукына сылтама белән күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә, смортларда экспонатларны күрсәткәндә, реклама максатларында, гариза бирүче тарафыннан мәгълүмат билгесеннән файдалану булып тора.

14. Азык-төлек продукциясенә мәгълүмат билгесен төшерү бу Нигезләмә, Тәртип һәм Таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 21 ноябрь, 896 нчы
карары белән расланды

Азык-төлек продуктларының сыйфатын яхшырту һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара яраштыру советы турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Азык-төлек продуктларының сыйфатын яхшырту һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара яраштыру советы (алга таба – Яраштыру советы) Татарстан Республикасы территориясендә азык-төлек продуктларының сыйфатын яхшырту һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының, «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең (алга таба – Республика сыйфат үзәге), азык-төлек продуктлары, материаллар һәм әйберләр (алга таба – азык-төлек продукциясе) җитештерүчеләр һәм аларның берләшмәләренең, эшкәртү, сәүдә, эксперт һәм башка оешмаларның нәтиҗәле хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында оештырыла торган күмәк киңәшмә органы булып тора.

1.2. Үз эшчәнлегендә Яраштыру советы федераль закон, Татарстан Республикасы законнары һәм бу Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

1.3. Яраштыру советы бурычлары – Татарстан Республикасында азык-төлек продуктлары сыйфатын яхшыртуны һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү системасын оештыру, «Милли сәүдә маркасы» системасын үстерү юнәлешләрен һәм аны камилләштерү буенча тәкъдимнәрне, система эшчәнлеге барышында барлыкка килә торган мәсьәләләрне карау.

1.4. Яраштыру советы составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2. Яраштыру советының төп вәкаләтләре

2.1. Яраштыру советы үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

Татарстан Республика территориясендә азык-төлек продукциясенең сыйфатын яхшыртуны һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүгә, аны җитештерүгә һәм әйләнештә йөртүгә кагылышлы мәгълүматны һәм статистик һәм башка материалларны анализлый;

Татарстан Республикасында азык-төлек продукциясенең сыйфатын яхшырту һәм куркынычсызлыгы буенча чаралар эшли;

халыкка азык-төлек продукциясе сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре турындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чаралары һәм (яки) мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша хәбәр итә;

түбәндәгеләр буенча тәкъдимнамәләр әзерли:

Татарстан Республикасы территориясендә «Милли сәүдә маркасы» мәгълүмат билгесе төшерелгән азык-төлек продукциясе чыгаруны һәм сатуны арттыру;

кеше сәламәтлеге һәм тормышы өчен зарарлы азык-төлек һәм башка өстәлгән әйберләрне, шулай ук азык-төлек продукциясен фальсификацияләү фактларын ачыклау максатларында, яңа тикшерену төрләрен үткәрү;

азык-төлек продукциясенең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә норматив хокук актларын камилләштерү.

2.2. Яраштыру советы үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

азык-төлек продукциясенең сыйфатын яхшыртуны һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте органнарыннан, оешмалардан һәм гражданнардан соратып алырга;

Яраштыру советы компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый һәм башка кызыксынучы оешмалар вәкилләрен һәм гражданнарын утырышларга чакырырга;

экспертларны, шулай ук фәнни-тикшерену, проект һәм мәгариф оешмалары вәкилләрен билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә;

азык-төлек продукциясенең сыйфатын яхшыртуны һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча эшче төркемнәр, комиссияләр төзергә.

## 3. Яраштыру советы эшчәнлеге белән җитәкчелек итү һәм аны оештыру

3.1. Яраштыру советы составына Яраштыру советы рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм әгъзалар керә.

3.2. Яраштыру советы рәисе:

Яраштыру советы эше белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

тәкъдим ителә торган көн тәртибен раслый һәм Яраштыру советы утырышлары беркетмәләренә имза куя;

юнәлешле оешмаларга, хакимият органнарына һәм гражданнарга тиешле сораулар, аңлатмалар, мөрәҗәгатьләр җибәрә;

Яраштыру советы компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча Яраштыру советын дәүләт, муниципаль, иҗтимагый һәм башка оешмаларда, учреждениеләрдә, ведомстволарда тәкъдим итә;

аерым вәкаләтләрен Яраштыру советы рәисе урынбасарына тапшырырга хокуклы.

3.3. Яраштыру советы рәисе урынбасары, Яраштыру советы рәисе булмаганда, аның функциясен башкара.

3.4. Яраштыру советы сәркатибе Яраштыру советының эш башкару эшләрен алып бара, шул исәптән утырышлар беркетмәләрен рәсмиләштерә.

3.5. Яраштыру советы эшчәнлеген оештыру, матди-техник һәм мәгълүмати-методик яктан тәэмин итү тәкъдим ителә торган башкарма хакимият органы вәкаләтләре чикләрендә Яраштыру советы рәисе тәэмин итә.

## 4. Яраштыру советы эше регламенты

4.1. Яраштыру советы утырышлары, кирәк булуга карап, кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

4.2. Яраштыру советы утырышына документлар Яраштыру советы сәркатибе тарафыннан әзерләнә һәм совет әгъзаларының утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

4.3. Яраштыру советы утырышы, әгәр дә анда әгъзаларының яртысыннан күбесе катнашса, үткәрелгән дип санала.

4.4. Яраштыру советы утырышын – Яраштыру советы рәисе, ул булмаган очракта, аның кушуы буенча рәис урынбасары үткәрә.

4.5. Яраштыру советы карарлары, утырышта катнашучы саныннан чыгып, гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, хәлиткеч тавыш булып рәис тавышы санала.

4.6. Яраштыру советы карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәгә Яраштыру советы рәисе һәм сәркатибе кул куя.

Утырышта карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча үз фикере булган Яраштыру советы әгъзасы аны утырыш беркетмәсенә кертүне таләп итәргә хокуклы.

Кызыксынучы оешмалар һәм гражданнар үтенече буенча аларга мөрәҗәгать иткән көннән өч эш көне эчендә Яраштыру советы утырышы беркетмәсеннән күчермә бирелергә мөмкин.

4.7. Яраштыру советы әгъзалары Яраштыру советы утырышында үзләре катнаша. Яраштыру советы әгъзалары булмаган затларга тавышларны тапшыру рөхсәт ителми.

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 21 ноябрь, 896 нчы
карары белән расланды

Азык-төлек продуктларының сыйфатын яхшыртуны һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча ведомствоара яраштыру советы
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, Яраштыру советы рәисе |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры, Яраштыру советы рәисе урынбасары |
| Булгаков Олег Михайлович | «Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының башкарма директоры, Яраштыру советы сәркатибе (килешү буенча) |

Яраштыру советы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдреева Юлия Ивановна | Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |
| Авдонина Любовь Геннадьевна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Әхмәтханов Җәүдәт Йосыф улы | Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе җитәкчесе |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Камалов Рөстәм Илдар улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министрының беренче урынбасары |

| | |
|---|---|
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Мостафин Айрат Рафинант улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе башлыгы |
| Осипов Сергей Альбертович | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары |
| Сафиуллин Илсур Миннур улы | «Милли сәүдә маркасы» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры |
| Сибгатуллин Рөстәм Рәфкать улы | Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары |
| Туктаров Фәрид Хәйдәр улы | «Татарстан Республикасында стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар дәүләт төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Хисаметдинов Алмаз Гаптрәүп улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы – Татарстан Республикасының дәүләт баш ветеринария инспекторы |
| Хәбипов Нурислам Нуриман улы | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шәрипова Гүзәл Азат кызы | Татарстан Республикасының мәдәният министры урынбасары. |